**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422600

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422600

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**26.10.2021** **№ 900**

**Биектау муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе төзү турында**

Территорияне тотрыклы үстерүне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү, территорияләрне планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктына, 31, 32, 33, 39, 40 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьяларына, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта нигезендә җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссия төзергә һәм расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Ф.Хисамутдинов

Кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 26 октябрендәге 900 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш буенча даими эшләүче комиссия СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Хәкимуллин Рамил Фатыйх улы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм ТКХ мәсьәләләре буенча урынбасары, комиссия рәисе |
| Минһаҗев Салават Марат улы | - Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, комиссия рәисе урынбасары |
| Әхмәтҗанов Адель Хәлил улы | - Биектау муниципаль районының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге баш белгече, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Архипов Владимир Димитриевич | - Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы |
| Хәсәнов Адель Рамил улы | - Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе урынбасары |
| Хөснетдинов Артур Мифтахетдин улы | - Биектау муниципаль районының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы |
| Территориясенә карата проект эшләнә торган авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча). | |